Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«28» октябрь, 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2021 елда яшәү урыны буенча Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 600 (алты йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 300 (өч йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1). Чишмәгә бара торган юлны ремонтлау.
2). Материал сатып алу һәм чишмәне ремонтлау.
3). Урамнарны яктыртуга лампалар сатып алу һәм аларны урнаштыру.

2. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Иске Дөреш авыл җирлеге Таулы Дөреш авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Дөреш авыл җирлеге Башлыгы Р.М. Дусадбеков